КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 14 ноябрь г.Казань № 1213

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм күрсәтүнең өстәмә чаралары турында» 2022 ел, 20 октябрь, 1122 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм күрсәтүнең өстәмә чаралары турында» 2022 ел, 20 октябрь, 1122 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу аркасында һәлак (вафат) булган гражданнар гаиләләренә ярдәм күрсәтүнең өстәмә чаралары турында»;

1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе милли гвардиясенең хәрби хезмәткәрләре һәм анда хезмәт итүче затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт итүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренә (гаилә

әгъзаларына), шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу аркасында һәлак (вафат) булган, югарыда күрсәтелгән категорияләрдәге гражданнар гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) (алга таба – гаиләләр) түбәндәге өстәмә ярдәм чараларын билгеләргә:»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек башкаручы эш бирүчеләргә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе милли гвардиясенең хәрби хезмәткәрләре һәм анда хезмәт итүче затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт итүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы хезмәткәрләргә бер тапкыр бирелә торган түләүләр рәвешендә өстәмә социаль гарантияләр билгеләүне, шулай ук аларның гаилә әгъзаларына өстәмә социаль ярдәм чараларын карауны тәкъдим итәргә.»;

3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе милли гвардиясенең хәрби хезмәткәрләре һәм анда хезмәт итүче затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт итүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренә (гаилә әгъзаларына), шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу аркасында һәлак (вафат) булган, югарыда күрсәтелгән категорияләрдәге гражданнар гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) (алга таба – гаиләләр) түбәндәге өстәмә ярдәм чараларын билгеләүне тәкъдим итәргә:»;

4 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

2. Бу карарның гамәле 2022 елның 20 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин